ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Пушкина, д.38, п.г.т.Уруссу, 423950

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Пушкин урамы, 38йорт, Урыссу ш.т.б., 423950

Тел.:(85593) 2-74-16, факс:2-62-20, e-mail:jutaza@tatar.ru, adm_jutaza@mail.ru, www: jutaza.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**«_23_»____11____ 2020г.** **№** 903

Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының "Урыссу поселогыннан 11 чакрымнан артык ераклыктагы һәм аз халыклы авыл торак пунктларына беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплау өчен Ютазы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү тәртибен раслау турында " 2018 елның 22 октябрендәге 731 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында " 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2020 елның 28 апрелендәге 18 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы район Советының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Башкарма комитетның 22.10.2018 ел, № 731 карары белән расланган Урыссу поселогыннан 11 чакрымнан артык ераклыкта урнашкан ерак һәм аз халыклы торак пунктларга беренче чиратта кирәкле товарларны китерү белән бәйле кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга Ютазы муниципаль районы бюджетыннан субсидияләр бирү Тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Тәртипнең 2 пунктындагы 2.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.5. Субсидия алу өчен Субсидия алучы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының территориаль үсеш бүлегенә түбәндәге документлар комплектын алып килә:

- Субсидия алуга гариза;

- Юридик затны дәүләт теркәвенә алу турында таныклык күчермәсе яисә юридик затларның бердәм дәүләт реестрына язма кертү турында таныклык алучы раслаган күчермә;

- Транспорт чаралары булуын раслаучы документлар (техник чара паспортының күчермәләре һ. б.);

- Беренче чиратта кирәкле азык-төлекне һәм тауарларны транспортлауга кирәкле ягулык-майлау материаллары сатып алу чыгымнарын исәпләү (беренчел документацияне теркәп);

- Субсидия алучыда Россия Федерациясенең салымнар һәм җыемнар турында законнары нигезендә түләнергә тиеш булган салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча бурычлары юклыгы турында белешмә.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә электрон челтәр массакүләм мәгълүмат чарасында http://yutazy.ru адресы буенча рәсми бастырып чыгару юлы белән (челтәр басмасы буларак теркәлү: № ФС 77 – 07.12.2011 ел, № 47613) урнаштырырга, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru адресы һәм http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет информацион-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитет җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

А. В. Сучкова

2-80-12